**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы турында» Указына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы турында» 2005 елның 21 июлендәге ПУ-298 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 15 ноябрендәге ПУ-479 номерлы, 2007 елның 3 октябрендәге ПУ-523 номерлы, 2008 елның 1 мартындагы ПУ-96 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-207 номерлы, 2010 елның 20 августындагы ПУ-544 номерлы, 2010 елның 13 декабрендәге ПУ-806 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-146 номерлы, 2012 елның 6 февралендәге ПУ-67 номерлы, 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы, 2012 елның 4 декабрендәге ПУ-1011 номерлы, 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-570 номерлы, 2014 елның 20 декабрендәге ПУ-1160 номерлы, 2015 елның 28 мартындагы ПУ-371 номерлы, 2016 елның 29 гыйнварындагы ПУ-60 номерлы, 2016 елның 3 мартындагы ПУ-223 номерлы, 2018 елның 24 декабрендәге ПУ-878 номерлы, 2019 елның 11 маендагы ПУ-272 номерлы, 2019 елның 2 ноябрендәге ПУ-667 номерлы, 2020 елның 14 маендагы ПУ-282 номерлы,2020 елның 11 августындагы ПУ-472 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы һәм 2022 елның 11 августындагы ПУ-545 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы (алга таба шулай ук – Совет) составында:

Совет составыннан Ф.Ә. Әгълиуллинны чыгарырга;

Совет составына Кадыйров Азат Рифгать улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын кертергә;

Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

М.С. Бәдретдиновның – «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы, Совет рәисе урынбасары»;

А.Г. Исаеваның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының хокукый мәсьәләләр һәм җәмәгать контроле комиссиясе әгъзасы (килешү буенча)»;

А.И. Нәфыйгинның – «Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе»;

б) Татарстан Республикасында дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы турында нигезләмәдә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның җиденче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 566